**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*2020 елның 4 августы* *275№*

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигез булган искәрмәләрне җайга салу буенча Килештерү комиссиясе төзү турында»

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хатында билгеле булган искәрмәләрне җайга салу максатларында (2019 15.11нән 10-53/14172 №),2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2004 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында» 191-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставына таянып, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хатында (2019 15.11нән 10-53/14172 №) билгеләнгән искәрмәләрне җайга салу буенча Килештерү комиссиясе (алга таба - Килештерү комиссиясе) төзергә.
2. Килештерү комиссиясенең эшчәнлек тәртибен расларга (1 нче кушымта).
3. Килештерү комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының https://alkeevskiy.tatarstan.ru/сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В.Юсупов

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 4 августы
275 номерлы Карары
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хатында (2019 15.11нән 10-53/14172 №) билгеләнгән искәрмәләрне җайга салу буенча Килештерү комиссиясе эшчәнлеге Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хатында (2019 15.11нән 10-53/14172 №) билгеләнгән искәрмәләрне үзара яраклы карарлар кабул итү һәм җайга салу максатында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итәргә вәкаләтле орган - Килештерү комиссиясен (алга таба - Килештерү комиссиясе) төзи.

2. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2016 елның 21 июлендәге «Территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документларын, килештерү комиссиясе составын һәм эш тәртибен килештерү тәртибен раслау турында»гы 460 номерлы боерыгына, Әлки муниципаль районы Уставына таяна.

3. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.

4. Килештерү комиссиясенең эш урыны — Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов урамы, 56 нчы йорт адресы буенча урнашкан Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Кабинеты.

5. Килештерү комиссиясе кирәк булган саен җыела.

6. Килештерү комиссиясенең чираттагы утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында комиссия әгъзаларына алдан 5 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

7. Килештерү комиссиясенең максималь эш вакыты аны булдыру датасыннан өч айдан да артмаска тиеш.

8. Килештерү комиссиясен төзү датасы - Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Килештерү комиссиясенең эшчәнлек тәртибен һәм составын раслау турында карарын Әлки муниципаль районының https://alkeevskiy.tatarstan.ru/ сайтында рәсми бастырып чыгару көне.

9. Килештерү комиссиясе утырышын аның Рәисе оештыра һәм алып бара, ә ул булмаганда - Килештерү комиссиясе рәисе урынбасары.

10. Килештерү комиссиясе утырышларында комиссия әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда Килештерү комиссиясе утырышларында гамәлдәге законнар нигезендә башка органнар вәкилләре катнаша ала.

11. Килештерү комиссиясе утырышы, әгәр анда исемлек составының кимендә 50% катнашса, хокуклы дип санала.

12. Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә Рәис һәм сәркатип кул куя.

13. Килештерү комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарга каршы тавыш биргән Килештерү комиссиясе әгъзалары аерым фикерне рәсмиләштерә алалар, ул беркетмәгә кушыла һәм аның аерылгысыз өлеше була.

14. Килештерү комиссиясе карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Килештерү комиссиясе Рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагылдырыла.

16. Үз эше нәтиҗәләре буенча Килештерү комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

16.1. Әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булган барлык кисәтүләрне исәпкә алучы үзгәрешләр кертү белән территориаль планлаштыру документы проектын килештерү.

16.2. Баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып торган сәбәпләрне күрсәтеп, территориаль планлаштыру документы проектын килештерүдән баш тарту.

17. Килештерү комиссиясе үз эше нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгына җибәрә:

17.1. Тәртипнең 16 пунктындагы 16.1 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, текст рәвешендәге һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендәге материаллар белән бергә кертелгән территориаль планлаштыру документы проекты.

17.2. Тәртипнең 16 пунктындагы 16.2 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, территориаль планлаштыру документының килештерелмәгән проекты, территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә, Килешү комиссиясе утырышы беркетмәсе, шулай ук текст рәвешендәге һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендәге материаллар.

Әлеге пунктның 17.2 пунктчасында күрсәтелгән документлар һәм материаллар үз эченә ала:

- килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турында тәкъдимнәр (шул исәптән, тиешле картада аларны аерып алу юлы белән килештерү вакытына кадәр килештерелмәгән мәсьәләләрне теркәү максатларында);
- Тәртипнең 16 пунктындагы 16.1 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне, территориаль планлаштыру документын раслаганнан соң, тиешле үзгәрешләрне территориаль планлаштыру документына кертү турында тәкъдимнәр әзерләү юлы белән килештерү планы.

18. Килештерү комиссиясе тарафыннан бирелгән беркетмәләр һәм материаллар нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Әлки муниципаль районы Советына килештерелгән яисә билгеләнгән өлештә килештерелмәгән территориаль планлаштыру документы проектын раслау яки баш тарту һәм аны эшләп бетерүгә җибәрә.

19. Килештерү комиссиясе адресына язма рәвештә килә торган гаризаларга һәм сорауларга җаваплар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда бирелә.

20. Килештерү комиссиясе карарларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В.Юсупов

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 4 августы
275 номерлы Карары
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хатында (2019 15.11нән 10-53/14172 №) билгеләнгән искәрмәләрне җайга салу буенча Килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Юсупов И.В. | Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Балакирев С. Н. | Рәис урынбасары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Камалов Р. А. | Комиссия сәркатибы, ТР Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |
| Комиссия әгъзалары | |
| Билялов Т.Ф | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары |
| Гарипов А. К. | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы |

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В.Юсупов